

# ТУГАН ЯК — РОДНОЙ КРАЙ

ГАЗЕТА СЕВЕРО-ЗАПАДА ОРЕНБУРГСКОЙ ОБЛАСТИ | № 2 (17) | 26 ЯНВАРЯ 2010

НОВОСТИ ТАТАРСКОГО МИРА

## «Оренбургские татары»

В Казани, в НКЦ, 22 января состоялась презентация книги известного автора, историка и педагога Рашита Искандарова «Оренбургские татары». В ней приняли участие: вице-премьер Правительства Татарстана Зиля Валеева, председатель исполкома Всемирного Конгресса Татар Ринат Закиров и другие руководители, видные общественные деятели. Как рассказал участвовавший в этом мероприятии депутат Законодательного Собрания Оренбургской области Ильдус Давлятов, все было организованно на высоком уровне, Казань принимала оренбуржцев как самых дорогих гостей. Но и наши земляки не остались в долгу. Была представлена широкая культурная программа, в которой участвовали и наши артисты, в том числе и асекеевцы.




В рамках этого события в Казани было организованно землячество оренбуржцев.

Ознакомиться с книгой можно в татарской автономии села Асекеево. Специально для этого, И.Давлятов закупил несколько десятков экземпляров.

## «Ак хисләр»

7 февральдә алтынчы мәртәбә безнең районда татар мәдәнияте фестивале «Ак хисләр» үткәрелә. Ул инде икенче ел төбәкара булып узачак. Чөнки Самара өлкә үзешчәннәре белән Оренбург өлкәсе артистлары ярышачак. Хәзерге көндә төрле районнардан сорау язулары килә.

Хөрмәтле Әсәкәй тамашачылары!

Сезне 7 февральдә сәгать 12 — дә район мәдәният йортына гала-концертка чакырабыз! Рәхим итегез!

## Шәхси мәктәп — беренче карлыгач

«Азатлык» радиосы хәбәр иткәнчә, 2007 нче елда Оренбурда яшәүче Элдар Языкбаев «Лингва» исемле үз мәктәбен ачып җибәрә. Бүгенге көндә анда тик инглиз һәм татар телләре генә укытыла. Мәктәпкә барлыгы 40 кеше йөри.

Мондый мәктәп ачу — Элдарның күптәнге хыялы була. «Ләкин кыенлыклар да җитәрлек бит. Беренчедән, арендага түләргә акча күп кирәк, икенчедән, дәреслекләр дә күп чыгым сорый», — диде яшь мөгаллим.

Педагогия университетының рус-инглиз бүлеген тәмамлагач ул дәүләт мәктәбендә эшли, аннан дәүләтнеке булмаган мәктәптә дә берничә ел укыта. Шуннан соң гына, тәҗрибә туплап, акча җыеп, үз мәктәбен ачуга иреша.

Бирелә татар телен өйрәнүчеләр төркеме барлыкка килгәнене әле 3 ай гына икән. «Ана теленә өйрәтү — ул минем күптәнге хыялым иде. Аны тормышка ашыру өчен миңа күп көч кирәк булды», — ди Элдар. — Мин рус авылында үстем, рус мәктәбендә укыдым, гаиләдә дә татар телендә сөйләшми иделәр. Шуңа күрә мин татар телен начар белә идем. Кинәт кенә башыма уй килде: ничек инде мин үзем татар кешесе, ә татар телендә сөйләшә белмим? Кызыксына башладым, күп укыдым, әбием янына Әсәкәй районына кайтып йөри башладым. Шулай итеп татар телен өйрәндем».

РЕПОРТАЖ






# СТУЖА ПЕСНЕ НЕ ПОМЕХА

Даже январская стужа не могла повлиять на горячие сердца артистов и зрителей, собравшихся на фестиваль «Халкым минем» в селе Алькино, Похвистневского района, Самарской области. Этот фестиваль проводился 23 января, в сельском Доме культуры и был организован Всемирным Конгрессом татар, телерадиокомпанией «Новый век» — Татарстан и национальным объединением «Туган тел» села Алькино.

Участвовать в фестивале — конкурсе приехали таланты из многих городов и сел: из Самары, Тольятти, Камышлы и Черемшан, сел Похвистневского района. Оренбуржье представляли Асекеевские артисты.

Жюри конкурса, возглавил который народный артист Татарстана Фердинанд Саляхов, пришлось делать не простой выбор (на снимке). Все участники фестиваля выступили отменно. И все же итоги были подведены. Гран- при получили черемшанцы. Надо отметить, что наши артисты выступили замечательно, под бурные аплодисменты благодарных зрителей. В номинации «фольклор» первое место занял коллектив «Чишма» Асекеевского дома культуры, в номинации «национальный танец» — танцевальная группа «Чишмы». Дипломантом конкурса стал Ришат Мухаметзянов из села Старомукменево, Асекеевского района. Он так же награжден путевкой на именитый международный конкурс «Урмай моны», который проводится в Чувашии. Фердинанд Саляхов высоко отозвался о способностях молодого певца.

В нашей газете мы довольно часто рассказываем о селе Алькино (Гали — авылы). Такое « знакомство» с соседями стало возможным благодаря созданию межрегиональной Ассоциации татарских объединений «Бердәмлек», в который вошли и асекеевцы, и бугурусланцы, и алькинцы. Во время перерыва председатель ТНКА Асекеевского района Ильдус Давлятов и председатель объединения «Туган тел» Расих Латыпов обсудили дальнейшие планы работы Ассоциации (**на снимке**).



**На снимке:** вручение призов.

ТУГАН ЯКТА

# ОРЕНБУР ШӘЛЕ

Оренбур шәле челтәрле бизәк,
Кышкы юллар төсле каймалар.
Язларымны хәтерләтә торган
Андый шәлләр тагын кайда бар?

Бу матур шәлләрне 82 яшьлек шәл остасы Рәшидә Зәйнулла кызы Мустаева бәйләгән. Аның шәлләрен безнең Әсәкәйдә яратып ябыналар. Рәшидә апа шәл осталары төбәгендә туып үскән кеше. Кечкенә чагыннан өйрәнеп үскән һөнәре аны картлык көнендә дә илһамландыра, тормыштан ямь табып яшәргә көч бирә. Шәл остасы Әсәкәй район мәдәният йорты директоры Зәйтүнә апа Валишинаның әнисе. Рәшидә апа Беляевка районы Донское авылында яши.

**Мәрфуга ТАЗЕТДИНОВА.**





ТВОРЧЕСТВО ЮНЫХ

# Школьные кутюрье

**В Старокутлумбетьевской средней школе Матвеевского района работает замечательный мастер своего дела Альфинур Ядкаровна Гайнулина. Двадцатый год она преподает уроки технологии у девочек, столько же лет ведет кружок «Золотая игла».**

Ее воспитанницы прекрасно вяжут, шьют, вышивают. И вот, учителя вместе с учениками, решили создать у себя в школе театр моды. Первое выступление театра было на смотре художественной самодеятельности в 2005 году. Тогда костюмы были сшиты из того, что приносили дети и учителя из дома. Выбрали девушек из разных классов для демонстрации одежды. Работали над походкой, умением наносить макияж, подбирали прически. На профессиональной основе работа пошла после посещения А.Я Гайнулиной областного семинара-практикума «Методика дизайнерского моделирования». Она привезла много интересных идей, проектов.

Второе дыхание театра моды «Яз геле» ( Весенний цветок) открылось осенью 2007 года. На первом районном детском фестивале татарской культуры, проходившем на базе Старокутлумбетьевской школы, была представлена коллекция национального татарского костюма. Благодаря помощи администрации Матвеевского района, школа закупила дорогую красивую ткань и все необходимое для новой коллекции.

В 2008 году «Яз геле» принимал участие на четырнадцатом региональном фестивале театров моды «Стиль 2008», который проходил в Сорочинске. На фоне городских коллективов — фаворитов, наш театр моды смотрелся ничуть не хуже. Именно поэтому приз от «Единой России» был вручен этому коллективу. Пропустив вперед только подобный театр из Бузулука, они заняли второе место в номинации «Этностиль». В конкурсе эскизов работа А. Кагармановой заняла первое место в номинации «Юный художник –модельер». За эскиз, А.Я. Гайнулиной был вручен Диплом третьей степени.

А в 2009 году юные модельеры принимали участие в областном смотре — конкурсе «Этнографическая мозаика Оренбуржья» и приехали с заслуженной победой.

В нынешнем году коллектив вновь примет участие в конкурсе моды «Стиль 2010».

В настоящее время в театре занимаются и радуют своими успехами Лилия Хамидуллина, Юлия Хамидуллина, Гульназ Абдрахманова, Эльвира Закирова, Нурия Сайфуллина, Дания Рузанова, Алина Хуснутдинова. Ждем от них новых побед!

**А.НИЗАМОВ.**
**Матвеевский район.**

ТУГАН ЯКТА



# Юл күрсәтүче йолдыз

Җир йөзендә һәр төбәкнең үзенә булган гүзәл сыйфатлары, табигать матурлыгы бар: бөек таулары, яшел урманнары, елгалары, үрнәк булырдай хезмәт ияләре, нәфис затлары бар. Мин дә сезнең рөхсәтегездән файдаланып, сезне, «Туган як» укучыларын үзебезнең якларга алып китәсем килә. Дим елгасының борылып-борылып, ургылып-ургылып аккан җирләренең берсендә урнашкан, безнең, матур Нәүрүз авылына.

Авылыбызны беренче атлап кергәч, сокланмыйча калган кеше юктыр. Сокланырлык та шул! Киң урамнары, матур йортлары, бай табигате белән таң калдыра ул. Әлбәттә, гүзәл авылыбыз данлыклы, эш сөючән кешеләргә дә бай. Шуларның берсе — Зәбидә апа Мустакимова. Аның тормыш юлы белән танышканнан соң, шуны аңладым: ул бик тирәннән, Галимҗан Ибраһимов әйтмешли,тормыш төбеннән күтәрелгән кеше. Язмыш Зәбидә апаны сабый чактан ук үзенең авырлыклары белән сынап торган. Алты айдан ул әнисез кала. Вакыт үтү белән әтисе өйләнеп Урта Азияга чыгып китә. Кечкенә кызчык Зәбидә Дусмәт авылындагы әби белән бабасы карамагына кала. Шушы авылда 7 класс белемне алгач, Зәбидә апа Ырымбур өлкәсенең Татар Каргалы авылына китә. Аннры әтисе чакыруы буенча Самаркандка бара. Мәктәп яшьтәге балалар укыту училищасын тәмамлап, кәрсәтмә буенча, ятим балалар йортына тәрбияче булып китә. Әмма туган як, туган җирләр аны үзенә тарта. Чын күңелдән туган ян җаны булганга күрәдер дә инде, Зәбидә апа 27 ел гомерен Науруз мәктәбендә балаларга юл күрсәтүче йолдыз сыман, пионер дружинасының җитәкчесе булып эшли.

Шушы гомер эчендә нинди генә кыенлыклар, авырлыклар очрамый аңа. Әйтергә кирәк, эшкә керү белән, ул иң беренче адым итеп үзенә максат куя — дружинага якташыбыз Муса Җәлилнең исемен бирергә. Анда гына тукталып калмый, балаларга язучының апасы Хәдичә белән очрашулар уздыра, хат язышалар. Шул вакытта төрле төбәк пионерлары белән хат алышалар. Үзбәкестан, Украина, Башкортостан, Әзербайҗан, Молдова, хәтта Таҗикстаннан да хатлар килә.

Әйтергә кирәк, Зәбидә апа барлык эшен туган төбәкнең тарихын, туган якларын белү, үзләштерү максатына багышлый. Ул үзенең бер очрашуында: «Без һичшиксез үзебезнең үткәнне белергә тиеш, югыйсә безнең киләчәгебез юк», — диде.

Ирексездән, күз алдына чәчкәдән чәчкәгә очып, татлы бал җыючы нечкәбил бал корты күз алдына килә. Зәбидә апа да, гомер юлын шулай авыр тормыш сынауларына бирешмичә, сынмыйча, сыгылмыйча һәрвакыт сәхнәдә биеп, балалар белән эшләп, хезмәттәшләренә ярдәм итеп, үрнәк булып яши. Ике кыз, бер ул үстерде. Хәзер инде аның оныклары, онықчасы да бар. Шәхси тормышында Зәбидә апа Фәррәховна кебек җыйнак, тәртипле, итәгатьле, эш сөючән, һәрвакыт ачык-тигез мөнәсәбәтле, туган җиренә мәхәббәтле кешеләр күбрәк булсын иде. Шунда безнең Туган як, Туган җир суынмас, мәңге сакланыр иде.

**Рузилә НАСЫЙРОВА,**
**Пономаревка районы,**
**Нәүрүз авылы.**

ХӘТЕР

# «Ана» турында баллада

2010 елның 9 маенда Бөек җиңү бәйрәменә 65 ел тула. Һәр гаиләгә керде ул ачы сугыш еллары. Күпләр мәңгегә үзләренең башларын салып калдылар ерак кырларда. Шуңа күрә дә Бөек Ватан сугышы мәңгегә чыкмый күңелдән. Минем хәтергә «Ана» турында баллада килеп төште һәм аны «Туган як» гәзитәсе укучыларына тәкъдим итәсем килә.

Бер сугышка өч ул бирде,
Кайтмады өчесе дә.
Ялгыз әйдә, ялгыз ана,
Юк шул бер кешесе дә.

Өч улын көтеп арыгач,
Дөнья куйды карты да.
Ялгыз әйдә, ялгыз ана,
Яше җитмеш алтыда.

Капка төбенә чыга да
Юлларга карый ана.
Өч улы өч юлдан беркөнне
Кайтырлар кебек аңа.

Кояш баешлары моңсу,
Моңсу басу юллары.
Шул кояш баешларында
Калды газиз уллары.

Кояш баешына карап,
Уйлана ялгыз ана.
Кояш баешлары кызыл
Әйтерсең,дөнья яна.

Дөнья янмый, йөрәк яна.
Йөрәк яна ярылып.
Ана гына үз баласын
Көтә шулай зарыгып.

Кайтмасын белсә дә көтә,
Ана күзе юлларда.
Чикләвек китереп куя
Кайтмый калган улларга.

Кояш чыга, кояш байый
Көннәрне сүтәр өчен.
Аналар яши дөньяда
Улларын көтәр өчен.

**Ф.КАЛИМУЛЛИНА, Матвеевка авылы.**

# МАЛАЙ ЧАГЫМНЫҢ КАЙБЕР ХАТИРӘЛӘРЕ

**(Дәваме. Башы 11 санда).**

Тагын шунысы мин кечкенә малайның хәтерендә уелып калган. Кырык җиденче еллар тирәсе булгандыр. Арыш урагына төшкәннәр иде инде. Әнием һәрвакыттагыча, көнне төнгә ялгап, кырда бәйләүдә. Әтием трактор белән басуда. Ялгышмасам бердәнбер булган «Коммунар» комбайнын тарттыра иде. Ул ура һәм бастыра торган аппарат бик иске, әледән-әле ватыла, я инде «мотор» дигән нәрсәсе пошкыра-пошкыра да, сүнә.

Әлегедә гарип әтием, комбайнер белән аны төзәтеп җәфаланалар. Без, малайлар, иптәшләрем белән җае чыкканда комбайн бункерына утырып йөрибез. Әтием анысына чик куйды:

— Өйдә дә эш күп, син зур малай, әбиеңә ярдәм ит, бүтән монда буялып йөрмә! — диде.

Мин кайтып авыл урамына кергән идем инде, каршыма күршем Рөстәм очрады. Кулына кечкенә генә төенчек тоткан, бер кулында әллә шешә белән сөт, әллә катык. Кырга әнисенәме, әтисенәме төшке аш илтергә бара иде. Ул мине күрүгә, кычкырып җибәрде:

— Рәмис, малай, йортыгызга милитсә төшкән, йөгер!

Чын милиционерны күргәнем булмаса да, мәктәп залында рәсеме бар иде. Ул мыеклы, кулбашындагы погонында йолдызы да бар иде бугай. Башында кызыл буйлы, өсте минем әнинең он чиләге чамалы, фуражка.

Тик миңа шунысы билгесез: ул йортка ничек төшә икән? Түбәне тишепме, тәрәзәдәнме, әллә ишектәнме? Һәм ни өчен төшә? Шулай уйланып өйгә таба йөгердем.

Кайтып җитсәм тарантаска җигелгән, председатель генә йөри торган колхоз айгыры безнең капкага бәйләнеп, ал аяклары белән җир торнап тора. Ак чәчле Гайнекамал әбием кулларын күкрәгенә куеп, бик хафаланган кыяфәттә ачык өй алды ишегеннән каядыр әкчә карап тора иде.

Ул мине күрү белән: «Балам, өйгә кермә, милатсә бар, усал, бәреп-нитеп йокмасын үзеңне, күзеңә ак-кара күренми», — диде.

Кызыксынуым көчле иде, ничек итеп милиция йортка төшкәнен күрәсем килде. Ишектән әбием уздырмагач, тәрәзәгә барып, чыгып торган нигез ташына басып, әчкә күз салдым.

Иң башлап күзем әбием белән бергәләп суккан «диргүгә» җәелгән сәкегә, сәке өстендәге ялт-йолт күзен уйнатып, курку катыш кызыксыну белән нидер күзәткән Динар энемә төште. Карый торгач, тузанлы өй эчендә, сәке астыннан чыгып торган галифе зәңгәр чалбар кигән күн итекле аякларны күреп алдым.

Өйдә күп нәрсә тузынган, бабам ясаган бердәнбер урындык ауган. Мич артындагы балалар (без) йоклый торган якны каплап тора торган, әнием алып килгән (зурая төшкәч кенә белдем) кизүле суккан чаршау бер як баныннан өзелеп төшкән. Аны, авыл советы председателе вазифасын башкарган, үз фамилиясен язганда да берничә хата җибәрә торган, сугыш арты чорында белемле кеше булмау сәбәпле бу хезмәткә билгеләнгән, Закир агай өй базына төшә торган такталарны ачып тора иде.

Милиционер әнинең мичтән көл тарта торган, тимерче Әхмәтҗан абый ясап биргән кисәү агачы белән, иске итек балышын, ыңгырчак, чабата калыпларын, әбиемнең безгә бияләй, оекбаш бәйләү өчен йон эрли торган каба төбен, тагын әллә нәрсәләр тартып чыгарды да, тәмам тузанга батып, үзе дә килеп чыкты. Җиңнәрен сызганган, аксыл-яшел күлмәктән йөзе кызарып тирләп төшкән, ләкин, мәктәп залында мин күргән рәсемдәге милиционердан аермалы булар мыегы юк иде. Ул теш арасыннан төкерде дә:

— Все равно найду! — диде. Аннары «Спускайся в погреб!» дип, сәвит председәтеленә әмер бирде.

Закир агай «Чава? Чава?», — дип, нидер әйтмәкче булган иде, милиционер үзе базга төшеп китте. Ул да булмады, базда нидер шакылдаган тавыш килде, яман сүгенү сүзләре ишетелде: караңгыда баз әрлегенә башын бәрде бугай.

Әллә шул тавыштан куркып, тәрәзә тупсасыннан ычкынып, җиргә чалкан килеп төштем.

Тиз генә килеп әбием:

— Балам, ни булды, кай җирең авырта? — дип, миңа торырга булышты. — Монда торма, бар, Вабиль эненә күз-колак бул, ул әнә тегендә сарай күләгәсендә йоклый.

Ул арада бригадир ике тәгәрмәчле «таратайка» арбага утырып, бабамны кырдан кайтарып китте. Аның борчылуы йөзенә чыккан иде.

— Ни булды, милитсә нәрсә эзли? — дип, сорады ул әбиемнән.

— Сорама инде, атасы, киленме, синме арыш алып кайткансыз дип жалу биргәннәр булса кирәк...

Ул арада өйдән милиционер белән Закир агай килеп чыктылар.

— Ну, старый, где спрятал рожь, покажи! — дип, формалы абзый тупса ташы кырына берәм-сәрәм сибелгән арышны күрсәтте.

— Руж ни таскал... — диде бабам, хәтсез аптырап торгач.

Ындыр артында безнең унсигез сутыйлап бәрәңге җиребез бар иде, шуның яртысына бабам яз алдында колхозда эшләп, эш көненә алган аз-маз арышны саклап, килеп чәчкән иде. Шуннан кайткан саен бабам тупсадагы ташка утырып, чабатасын салып кага торган булган. Нигә инде ул колхоз әйберенә яки кеше әйберенә тисен! Ул башкаларның читән буенда үскән кураен да мал куарга дип, сындырып алмаган. Шундый гадел һәм диндар кеше булган. Гөнаh була дип, гомеренә бер тапкыр да үзен фоторәсемгә төшертмәгән. Николай патша хезмәтендә булып, герман-рәсәй сугышында катнашкан. Хәтеремдә, уң як яңагында, озын гына колыч очы яралаган эз бар иде. Сөйли иде бабам: яраланып госпитальга элеккәч, Николай патша палатага кереп, ашау-эчү мәсьәләсен һәм башка якларны бездән сорашты дип. Шунысын да беләм: патшага хезмәт иткәнсең дип, Совет хөкүмәте, бабамны пенсиягә чыгармаган.

Бабам кулы белән ындыр ягына күрсәтеп:

— Там, наш руж, малайкалар мал-мал ризәли и кушал — диде.

Милиционер Закир агайны һәм бабамны ияртеп, ындырга менеп китте. Энем Динар белән без дә иярдек.

Арыш әчминнеген хәтсез урап йөрде, тотып-тотып иснәп тә карады, закон кешесе. Чынлап та, мал-туар тигән урында башаклар аз гына кыркылган иде.

Яңадан ишек алдына кайттык. Милицонер нидер исенә төшереп, мал абзарына кереп китте. Анда утырган тавык,очып чыкты да, дөнья буена кыткылтарга тотынды. Аңа, койрыгын күрше эте өзгән әтәчебез кушылып, ишек алды шау тавышка әйләнде.

Кечкенә арбасында йоклап яткан энем уянып, ул да бу «канонадага» кушылды.

Минем дә абзарга кереп карыйсы килде. Бер почмакта, кыштан калган ике кочак камыш печәненнән әйләндереп ташлап, җирне суккалап та типкәләп, кар базына төшеп менгәч, бу галәмәт хәлдән борчылган әбием белән бабамнан гафу да сорамыйча, милиционер капка ягына китте.

Сәвит председателе Закир агай:

—Миңнулла абзый, берәр ачулы кешегез бар идеме әллә, нигә җалу бирделәр икән? — дип сорады. Бабам:

—Юк иде ләбаса — диеп, тузан туздырып урам буйлап киткән тарантас артыннан, капканы ябып куйды.

Үсә төшкәч белдем инде: бер уч арыш тапкан булсалар шул чакта, әнием яки бабам,биш-ун елга китәселәре булган икән.

Шунысы да соңыннан ачыкланды: иң зур рольне бу вакыйгада әбием уйнаган булып чыкты.

Урак чорында һәрвакыттагыча авылда әби-чәби, бала-чагадан башка кеше калмаган. Шуннан файдаланыптыр инде, бер агай , колхоз ревизоры , көпә-көндез өч-дүрт тулы капчыкны өенә кайтарган. Каплаган саламы коелып калу сәбәпле, капчыклары күренеп яткан. Әбием бу хәлне күргәч, күрше-тирә апаларга сөйләнгән. Шуннан артык узмаса да, әҗерен шулай итеп түләргә туры килгән.

Яшерен түгел: ул чорда склад мөдире, ревизорлар, бригадирлар һәм калган авыл куштаннары бер булып урлашканнар, колхозны сауганнар (хәзер дә читкә куймыйлар кебек!). Бергә ашаганнар, бергә эчкәннәр, базарга алып барып, йөк-йөк он сата торган булганнар. Ә күңел биреп колхозда эшләгән халык ач булган. Чөнки, күп очракта икмәкне бер эш көненә,200-300 грамм бирә торган булганнар. Шулай ук, шул чор балаларына, кар эрегәч бәрәңге җиреннән җыйган, үткән елдан калган черек бәрәңге коймаклары ашарга туры килде. Алабута күмәчен дә татыдык (тәме әле дә хәтеремдә).

Тагын да шунысын язып үтәсем килә: ничек колхоз эшеннән кала алгандыр, белмим, әнием белән кечкенә арба тартып, без дән 4-5 чакрым чамасы урманга утынга бардык. Көн эссе, кояш кыздыра. Көннең буе чытыр, ботак эзләп сусап беткәнбез. Утынны төяп урманнан чыккан да, күрше мукшы авылындагы, трактор бригадасына тап булдык. Сусаудан күзләрем җемҗем итә башлаган иде минем. Бригадага су китерүче агай, без урысча бер сүз белмәсәк тә, безне күргәч, эшнең нәрсәдә икәнлеген бик тиз аңлады. Бик зур ябалдашлы, әрекмән яфраклары белән каплап куелган агач мичкәдән безне салкын, көмеш су белән сыйлады. Әй генә лә, суның кыйммәтлеге һәм тәме, сусаган чакта гына беленә икән!

Арып-талып өйгә кайтып кергәч, әбием мине йомырка белән сыйлады. Ул бер йомырканы минем өчен генә әбием самовар капкачын ачып, чүпрәккә төреп салып пешергән.

Ул минем өчен бик зур сый иде! Чөнки, 3-4 тавыгыбыз салган әз-мәз йомырканы ашамыйча атна буена җыеп, якшәмбедә, әнием 12 чакрымдагы район базарына җәяүләп сатарга алып китә. Шулай итеп безгә, күлмәкыштанга аз-маз кара һәм ак ситса отрезы сатып алып кайта торган булган. Башкача акча килер җир юк. Халыкның эшләгән эш көне өчен, таяк кына «түләнгән». Ә хөкүмәтебез салган налоглар, һәртөрле түләүләр, йомырка, ит, сөт заданияләре күп булган. Үләм, шартлыйм дисәң дә ышанмаганнар, ул түләүләрне бугазлап диярлек, алганнар. Түли алмасаң, азакы кәҗә, сарыгыңны алып чыгып китә торган булганнар.

Шуңадыр инде без, урамдагы үсмер малайлар, барыбыз да арыклар, озын муенлы, ач йөзләләр идек. Мин хәтерлим һәрчак тамагым ачыгып йөргәнен.

Без, бәлки, Сталин чорының «бәхетле балалары» шулай ачлы-туклы, ялан аяк, ялангач үскәнбез. Кияргә кием булмаган, ашарга да такы-токы гына. Кара яздан, «чебиләп» чыккан аякларыбыз белән, ялан аяк көзгә килеп керә идек. Салкыннар җиткәч, карлы-яңгырлы пычрак көннәрдә, чабата табаныннан аякка су үтә. Оста бабам безгә чабата табанына юкә белән агач шакмаклар беркетеп бирә. Алдынаартыңа карабрак, ипләберәк басып йөрсәң, мәктәпкә шулай да коры аяклар белән барып җитәргә була... Ләкин, кая инде ул алны-артны уйлау, күлдәвекнең уртасыннан чабабыз! Ә инде мәктәпкә килеп кергәч, коридорның такта идәненнән шакы-шокы, лап-лоп чабулар!.. Менә кайда шау-шу, менә кайда мәхшәр!..

Мәктәбебез авыл байларыннан калган дүрт-биш бүлмәле агач йортта урнашкан. Һәр класста «голландка» мич. Мәктәпне караучы, җыештыручы, мичләрне ярты төннән ягучы да,ире сугышта югалып калган Гөлфания апа иде. Ничек кенә берүзе өлгерә алды икән барсына да! Җылы әрәм булмасын дип, мич яныл беткәнче үк, юшкәләр кай чакта ябылган булыр иде. Шуңа күрә, дәрес вакытында балалар исерә, башлары авырта иде.

Дәрес бирүче укытучарыбыз да күбесенчә ун класс бетергән апалар.

Ул чорның җитешсез фәкыйрь тормышында, йорт-җир тирәсендәге, колхоздагы бетмәстекәнмәс эшләр, мәшәкатьләр белән талчыккан, үзләре дә аз белемле укытучыларыбыз мәктәпкә килгәч, балаларга дәрес биргәндә, еш кына йоклап утыралар иде. Шуңадыр да, күпләребезгә, кайбер предметларның «азы» да эләкмәде. Бик азларыбызга укуны дәвам итеп, югары белем алу насыйп булды...

**Рамис ГИЗАТОВ,**
**Яңа Тирес авылы,**
**Абдулин районы.**

# ТЕКСТЫ ПОПУЛЯРНЫХ ТАТАРСКИХ ПЕСЕН

## Аерылмагыз

Су буенда ялгыз аккош,
Каерылган канатлары.
Канатларны каера ул
Аерылу газаплары.

Аерылмагыз, аерылмагыз,
Булса да сәбәпләре.
Канатларны каера ул
Аерылу сәгатьләре.

Ят кошны пар итмәс аккош,
Ялгыз канат какса да.
Без дә бергә булалмабыз,
Сулар үргә акса да.

Ялгыз аккош күргән саен
Өзелә бәгырьләрем.
Нигә без бергә чакларның
Белмибез кадерләрен?!

Су буенда ялгыз аккош,
Каерылган канатлары.
Канатларны каера ул
Аерылу газаплары.

Аерылмагыз, аерылмагыз,
Булса да сәбәпләре.
Гомерләрне кыскарта ул
Аерылу сәгатьләре.

## Су буенда учак Яна

Тып-тын калган төнге авыл,
Йоклый авыл, сүнгән уты.
Кайттым сиңа еллар узгач,
Хәтер уйный, керми йокы.

Су буенда, учак яна,
Кем кабызган ул учакны?
Төшсәм әгәр су буена,
Табармын күк балачакны.

Тыныч сулап йоклый авыл,
Йөрим төнге урамында.
Таныш сукмак, таныш кое —
Утсыз да мин күрәм монда.

Су буенда учак яна,
Сүнмәс микән таңга чаклы?
Урамыңда, туган авылым,
Табармын күк балачакны.

Хәтерләсәң, онытмасаң,
Мин башканы өмет итмим.
Ялантәпи урамыңда
Уйнап үскән балаң бит мин.

Су буенда учак яна,
Хәтирәләр тәсле якты.
Кайттым кебек яшьлегемә,
Табармын күк балачакны.

# ПРОГНОЗ ПОГОДЫ

| ЯНВ. | ДНЕМ | НОЧЬЮ | |
|---|---|---|---|
| 26 | $-17^{o}$ | $-17^{o}$ | Ясно |
| 27 | $-20^{o}$ | $-20^{o}$ | Ясно |
| 28 | $-25^{o}$ | $-26^{o}$ | Ясно |
| 29 | $-25^{o}$ | $-29^{o}$ | Ясно |
| 30 | $-7^{o}$ | $-23^{o}$ | Осадки |
| 31 | $-4^{o}$ | $-3^{o}$ | Осадки |

| ФЕВР. | ДНЕМ | НОЧЬЮ | |
|---|---|---|---|
| 1 | $-2^{o}$ | $-3^{o}$ | Осадки |
| 2 | $-7^{o}$ | $-6^{o}$. | Осадки |
| 3 | $-10^{o}$ | $-11^{o}$ | Осадки |
| 4 | $-7^{o}$ | $-10^{o}$ | Осадки |

**www.gismeteo.ru**

# ПОЗДРАВЛЕНИЯ

29 гыйнварда **Фәнүзә Хәби кызы ШАМСУТДИНОВАГА** 60 яшь тула. Сине шушы иң зур, шатлыклы бәйрәмең белән котлыйбыз! Сиңа озын гомер, шатлык, бәхет, киләчәктә балаларың белән оныкларыңнан игелек, шәфкать күреп, тормышка сөенеп яшәргә язсын.

Гомерләрең булсын бәхетле,
Бәхетләрең булсын гомерле.
Җирдә булган бөтен изгелекне
Бирсен Ходай сиңа бу көнне!

**Тормыш иптәше, кызлары: Динә, Зөлфия, Резеда, Гөлнара, кияүләре: Рәмил, Нәдир, Рәмил, Биш оныгың, ике оныкчаң.**



* * *

31 гыйнварда **ШАКИРҖАНОВ Әлфир Наиль улының** туган көне. Син ел башындагы зәмһәрир салкын вакытта тугансың. Табигатьнең, тереклекнең сынауларга дучар вакытында туры килгән туган көнең белән ихлас күңелдән котлыйбыз! Гыйнвар салкыннарында туган булсаң да, дусларыңа, хезмәттәшләреңә җылылык бирә торган кайнар йөрәгеңдә тагын да көч-кузт өстәлсен. Кышкы тәрәзәләрдәге бизәкләрдәй, күңелең матур, даладай киң булсын. Саулык, иминлек, ак бәхетләр, саф бәхетләр сиңа!

**Сине чын күңелдән котлыйлар барлық район мәдәният хезмәткәрләре.**

# ОБЪЯВЛЕНИЯ

Всемирный конгресс татар, татарская национально-культурная автономия Асекеевского района, отдел культуры администрации Асекеевского района и районный Дом культуры **проводят 7 февраля** в Асекеево **межрегиональный фестиваль-конкурс татарской культуры «Ак хисләр»** («Светлые чувства»).Председателем жюри является народный артист Татарстана, доцент музыкального факультета Казанского педуниверситета М. Галиев. Фестиваль проводится по номинациям татарская народная песня (соло, дует, группа), художественное слово, народный танец (соло, группа). Возраст участников от 15 до 35 лет. А так же фольклор, семейный ансамбль, игра на музыкальном инструменте. Возраст не ограничен. Заявки на участие и отборочный тур принимаются до 4 февраля. Справки по телефонам в Асекеево: **8(35-351) 21046, 22281.**

* * *

Уважаемые жители Абдулинского, Асекеевского, Бугурусланского, Матвеевского, Пономаревского, Северного районов! Продолжается подписка на газету «Туган як. Родной край» с доставкой со следующего месяца. Обратившись в отделение связи или к почтальонам, вы можете получать газету уже с февраля. Газета выходит два раза в месяц. Цена символическая.

* * *

Уважаемые подписчики газеты! Редакция **принимает заявки на публикацию поздравлений, благодарностей и объявлений**, в том числе и на татарском языке. Так как газета выходит два раза в месяц, просим делать заявки заблаговременно. Справки по телефонам **8 (35-351) 2 22 81 или 8-90-58-429-140.**

# ПРОГРАММА ТНВ

## ТАТАРСТАН

### ВТОРНИК
### 26 января

08:00 Хэерле иртэ!
10:00 Доброе утро!
11:00 Сертотмас урдэк
12:00 Жырлыйк эле
12:45 Колкеханэ
13:00 ТВ фондыннан
13:30 Халкым минем
14:00 Виктория. (100-я серия)
15:00 В роли себя
15:30 ТИН-клуб
16:00 Новости Татарстана
16:15 Хочу мультфильм!
16:30 Кучтэнэч
16:45 Яшьлэр тукталышы
17:15 Арабелла возвращается. (8-я серия)
17:40 Музыкаль NON-STOP
17:50 Китэм, димэ...
18:45 Татарстан хэбэрлэре
19:00 Виктория. (101-я серия)
20:00 Кучтэнэч
20:15 Хочу мультфильм!
20:30 Новости Татарстана
21:00 Трубач. (10-я серия)
22:00 Татарстан хэбэрлэре
22:30 Концерт
23:00 Кучтэнэч
23:15 Хочу мультфильм!
23:30 Новости Татарстана
00:00 Крестная мать. (4-я серия.)
01:00 Волчица. (1-я серия)
02:00 Автомобиль
02:30 Трубач
03:20 Китэм, димэ...
04:05 ТВ фондыннан
04:30 Жырлыйк ?ле
05:15 Хосэенов. «Генеральная уборка»

### СРЕДА
### 27 января

08:00 Хэерле иртэ!
10:00 Доброе утро!
11:00 Мафиоза. (1-я серия)
12:00 Ватандашлар
12:30 Концерт. (Алтын читлек)
13:00 Китап
13:30 Яшэсен театр!
14:00 Виктория. (101-я серия)
15:00 Концерт
15:30 Путешествие вокруг света
16:00 Новости Татарстана
16:15 Хочу мультфильм!
16:30 Кучтэнэч
16:45 Син – минеке, мин – синеке
17:15 Арабелла возвращается. (9-я серия)
17:40 Музыкаль тэнэфес
17:50 Китэм, димэ...
18:45 Татарстан хэбэрлэре
19:00 Виктория. (102-я серия)
20:00 Кучтэнэч
20:15 Хочу мультфильм!
20:30 Новости Татарстана
21:00 Трубач. (11-я серия)
22:00 Татарстан хэбэрлэре
22:30 Кара-каршы
23:00 Кучтэнэч
23:15 Хочу мультфильм!
23:30 Новости Татарстана
00:00 Мафиоза. (1-я серия)
01:00 Волчица. (2-я серия)
02:00 Видеоспорт
02:30 Трубач. (11-я серия)
03:20 Китэм, димэ...
04:10 Син – минеке, мин – синеке
04:35 Китап
05:00 Яшэсен театр!
05:30 Концерт. (Алтын читлек)

### ЧЕТВЕРГ
### 28 января

08:00 Хэерле иртэ!
10:00 Доброе утро!
11:00 Мафиоза. (2-я серия)
12:00 Кэеф ничек?
13:00 Сэхнэ моннары
13:30 Туган жир
14:00 Виктория. (102-я серия)
15:00 Соотечественники
15:30 Путешествие вокруг света
16:00 Новости Татарстана
16:15 Хочу мультфильм!
16:30 Кучтэнэч
16:45 Арабелла возвращается. (10-я серия)
17:10 Музыкаль NON-STOP
17:25 Золотой гусь
18:45 Татарстан хэбэрлэре
19:00 Виктория. (103-я серия)
20:00 Кучтэнэч
20:15 Хочу мультфильм!
20:30 Новости Татарстана
21:00 Трубач. (12-я серия)
22:00 Татарстан хэбэрлэре
22:30 Татарлар
23:00 Кучтэнэч
23:15 Хочу мультфильм!
23:30 Новости Татарстана
00:00 Мафиоза. (2-я серия)
01:00 Волчица. (3-я серия)
02:00 Видеоспорт
02:30 Трубач. (12-я серия)
03:20 Сэхнэ моннары
03:45 М. Горький. «Кояш тошмэгэн жирдэ»

### ПЯТНИЦА
### 29 января

07:50 Жомга вэгазе
08:00 Хэерле иртэ!
10:00 Доброе утро!
11:00 Концерт. («Оныта алмыйм...»)
12:00 Мэдэният доньясында
13:00 Татар халык жырлары
13:20 Жомга вэгазе
13:30 Нэсыйхэт
14:00 Виктория. (103-я серия)
15:00 Путь
15:15 Бережно храня
15:30 Путешествие вокруг света
16:00 Новости Татарстана
16:15 Хочу мультфильм!
16:30 Кучтэнэч
16:45 Арабелла возвращается. (11-я серия)
17:10 Музыкаль тэнэфес
17:25 Бегемот Гуго
18:45 Татарстан хэбэрлэре
19:00 Виктория. (104-я серия)
20:00 КВН — 2009
20:30 Новости Татарстана
21:00 Мультфильм
21:15 Один день из жизни войны. (Фильм 1-й — «Жизнь, опаленная войной»)
21:45 НЭП
22:00 Татарстан хэбэрлэре
22:30 Син — минеке, мин — синеке
23:00 Кучтэнэч
23:15 Хочу мультфильм!
23:30 Новости Татарстана
00:00 Когда опаздывают в загс
01:40 Джазовый перекресток
02:10 Бои по правилам TNA
02:40 Двойной агент
04:10 Цену смерти спроси у мертвых
05:30 Нэсыйхэт

### СУББОТА
### 30 января

08:00 Татарстан хэбэрлэре
08:15 Новости Татарстана
08:30 ®
08:45 Путь
09:00 Путешествие вокруг света
10:00 Sина Миннэн Sэлам
11:00 ТИН-клуб
11:30 Выкрутасы «Шарма»
12:00 Е. Шварц. «Кар иле патшабикэсе»
13:00 Мужское дело
13:30 Видеоспорт
14:00 Адымнар
14:30 Яшэсен театр!
15:00 Ач, шигърият, серлэренне
15:15 Ж. Фэйзи. «Башмагым»
17:30 Мунча ташы
18:00 Канун. Парламент. Жэмгыять
18:30 Замужем — за Мужем
19:00 Дети Дюны. (6-я серия)
20:00 Мультфильм
20:35 Соотечественники
21:00 Среда обитания
21:30 Концерт. («Оныта алмыйм...»)
22:00 Татарстан. Атналык кузэту
22:30 Пора в санаторий «Бакирово»
22:35 Жырлыйк ?ле
23:15 Колкеханэ
23:30 Новости Татарстана. В субботу вечером
00:00 Семья кордье
01:40 Ночной музыкальный канал
03:40 Желтый фонтан
05:15 Дети Дюны. (6-я серия)

### ВОСКРЕСЕНЬЕ
### 31 января

08:00 Татарстан. Атналык кузэту
08:30 Новости Татарстана. В субботу вечером
09:00 Путешествие вокруг света
10:00 Sина Миннэн Sэлам
11:00 Замужем — за Мужем
11:30 Мультфильм
12:00 Тамчы-шоу
12:30 Яшьлэр тукталышы
13:00 Баскет-ТВ
13:30 Автомобиль
14:00 Ватандашлар
14:30 Татарлар
15:00 Татар халык жырлары
15:30 Мэдэният доньясында
16:30 Жизнь, судьба, любовь
18:00 Закон. Парламент. Общество
18:30 Мужское дело
19:00 Женщина-мушкетер
20:00 Мультфильм
20:20 Отдых по-бакировски
20:30 7 дней
21:30 Экэмэт кэмит
22:00 Кэеф ничек?
23:00 Батырлар
23:20 Дорога без опасности
23:30 7 дней
00:30 Видеоспорт
01:00 Дом Нины
03:00 Дорожные убийцы
04:25 Женщина-мушкетер

ТУГАН ЯК
РОДНОЙ КРАЙ
E-MAIL: tugan-iak-asekeevo@yandex.ru

**УЧРЕДИТЕЛЬ:**
ТАТАРСКАЯ НАЦИОНАЛЬНО КУЛЬТУРНАЯ АВТОНОМИЯ
**АДРЕС РЕДАКЦИИ:**
С.АСЕКЕЕВО, УЛ.ЧАПАЕВА 24.
**ТЕЛЕФОН:** (353-51) 2-22-81

Распространяется в Асекеевском, Абдулинском, Бугурусланском, Матвеевском, Пономаревском, Северном районах. Свидетельство о регистрации ПИ №ТУ 56-00065, выданное Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи и массовых коммуникаций по Оренбургской области.

ГАЗЕТА ОТПЕЧАТАНА В БУГУРУСЛАНСКОЙ ТИПОГРАФИИ.
461600, г.Бугуруслан, ул.Революционная, 14.
Цена свободная. ТИРАЖ: 2000 ЭКЗ.

**Главный редактор: Фарит НУГУМАНОВ**